**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«28» июнь, 2021 ел** **№ 81**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының 2020 елның 19 октябрендәге 16 номерлы карары (Советның 02.04.2021 №71 карары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре дип аталган 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә билгеләнә.

2. Биектау муниципаль районы вәкиллекле җирле үзидарә органының (алга таба - муниципаль район Советы) җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендәге вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен, шул исәптән Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләрне (өстәмәләрне) раслау;

муниципаль районның шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау;

- гамәлдәге законнар нигезендә башка вәкаләтләр.

3. Биектау муниципаль районы җирле үзидарәсе башкарма органының (алга таба - муниципаль районның Башкарма комитетының) җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендәге вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

төзелешкә рөхсәтләр бирү (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында һәм башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш);

муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда хәбәрнамәләр (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында һәм башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш) җибәрү;

территорияне планлаштыру документларын раслау (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында һәм башка федераль законнарда каралган очракларда);

муниципаль район территориясендә гамәлгә ашырыла торган шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасын алып бару;

муниципаль ихтыяҗлар өчен җирлек чикләрендә җирләрне резервлау һәм җир кишәрлекләрен тартып алу;

үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында я үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү яисә аны граждан законнарында каралган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерүне яисә аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерү.

җирлек чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру.

Әлеге Кагыйдәләр нигезендә муниципаль район башкарма комитеты вәкаләтләренә шулай ук түбәндәгеләр керә:

җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәтләр бирү;

капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга, рөхсәт бирү.

4. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарәсе башкарма органының (алга таба - җирлекнең башкарма комитеты) җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендә вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре документларын эшләүдә эшләү, ярдәм итү хокукында».

2) 14 статьяда:

а) 4 өлештә «капиталь төзелешнең» сүзләреннән соң «мондый рөхсәт бирү турында гариза кергән көннән унбиш эш көне эчендә әзерләнә һәм» сүзләре белән тулыландырырга;

б) 5 өлешне «комиссия» сүзеннән соң «модый фикер алышулар яки тыңлаулар тәмамланнган көннән унбиш эш көне эчендә» сүзләре белән тулыландырырга;

3) 15 статьяда:

а) 3 өлешне «2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 10.2 өлешендә башкасы каралмаган булса» сүзләре белән тулыландырырга;

б) 6 өлешнең 3 абзацын «территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү эшчәнлегенең» сүзләрен «территорияне комплекслы үстерүнең» сүзләре белән

алыштырырга;

2) 20 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге эчтәлекле ж) пункты белән тулыландырырга:

«ж) территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул итү.»;

б) 3 өлешнең 7 абзацын 9 нчы дип санарга;

в) 3 өлешне түбәндәге эчтәлекле 7 һәм 8 абзацлар белән тулыландырырга:

«вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы яисә Россия Федерациясе тарафыннан төзелгән һәм территорияне комплекслы үстерү турындагы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче юридик зат (алга таба - Россия Федерациясе тарафыннан билгеләнгән юридик зат);

Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы, территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул иткән җирле үзидарә органы, Россия Федерациясе субъекты төзегән һәм территорияне комплекслы үстерү турында Россия Федерациясе субъекты кабул иткән карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче юридик зат (алга таба - Россия Федерациясе субъекты билгеләгән юридик зат), яисә территорияне комплекслы үстерү турында карарны гамәлгә ашыру максатларында территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән зат тарафыннан.»;

в) 8 өлештә «утыз көн» сүзләрен «егерме биш көн» сүзләре белән алыштырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеге, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин